ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печишче авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

17.12.2025　　　　с. Русское Макулово　　　　03-01/49

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегендә
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 ст. нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Макыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе:　　　　Р.В. Гусева

Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
17.12.2025 ел,
№ 03-01/49 карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге Тәртип билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.01.2026 елдан 31.03.2026 елга кадәр гражданнар җыенында катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) мобилизацияләнгән гражданнар;

б) 1 төркем инвалидлар;

в) күпбалалы гаиләләр.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслау - приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Югары Ослан
муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
17.12.2025 ел № 03-01/49
карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________
Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И.А. и.
________________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
__________________________________________________________ нигезендә
Сезгә _______________________ вакытына кадәр
___________________________________________________ чараларны тормышка
ашыру өчен _____________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
______________________________________________
БИК алучының банкы _____________________________________
Сч. № __________________________________
Алучының сч. №__ . ________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО__________________
Түләүне билгеләү
_____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _______________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.А.и. ______________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________________
Алдым «__» _________________ 20___ ел. ______________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзеп алына торган өлеш тутырыла һәм Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*